Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № Х-12**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

"Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайты бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга таләпләрне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча рәсми сайтларын урнаштыруга һәм аларның бүлекләрен тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карарын исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бүлекләрен урнаштыруга һәм тутыруга кушымта итеп бирелә торган таләпләрне расларга (алга таба – Таләпләр).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм тутыру таләпләре белән эш итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
Х-12 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бүлекләрен урнаштыруга һәм тутыруга таләпләр**

I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - сайт) рәсми сайтының төп битендә «Коррупциягә каршы тору» исеме белән бүлеккә аерым гиперссылка (гиперсылтама) урнаштырылырга тиеш, ул бүлек коррупциягә каршы тору өлкәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары уздырган эш турында бөтен мәгълүматны үз эченә алган тиешле бүлекчәләргә ия.

«Коррупциягә каршы тору» бүлегенә керү гиперсылтама буенча эзлекле күчү юлы белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы сайтының төп битеннән гамәлгә ашырыла.

II. «Коррупциягә каршы тору» бүлеге мәгълүматын тулыландыруга таләпләр

1. «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы эше турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге мәгълүмат коррупциягә каршы көрәшнең түбәндәге юнәлешләренә багышланган сайтның аерым бүлекчәләренә эзлекле гиперссылкалар исемлеге рәвешендә бирелергә тиеш:

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе»;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция чагылышлары турындагы хәбәрләр өчен “Ышаныч телефоннары”;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы тору программасы»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге, аларны биләү коррупция хәвефе белән бәйле;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү (яраштыру) комиссиясе»;

«Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын, низагын) җайга салу комиссиясе»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затлар»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру чаралары турында хисаплар»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары уздырган муниципаль норматив хокукый актларның һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы нәтиҗәләре»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсенең органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актларга һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза»;

«Җәмәгатьчелек фикерен сораштыру, анкеталаштыру»;

«Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең коррупциягә каршы тору турындагы карарлары»;

«Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының коррупциягә каршы тору турындагы карарлары»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы тору турында муниципаль норматив хокукый актлары»;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы»;

"Методик материаллар, докладлар, хисаплар, күзәтүләр, статистик һәм коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча башка мәгълүмат".

«Коррупциягә каршы тору» бүлегендә шулай ук сайтның әлеге бүлегендәге башка бүлекчәләренә дә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затларының компетенциясенә бәйле рәвештә яисә сайтны оператив режимда коррупциягә каршы характердагы башка актуаль мәгълүмат белән тулыландыру кирәклегенә бәйле рәвештә урнаштырылырга мөмкин.

1.1. «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе» гиперсылтамасы буенча күчкәндә Татарстан Республикасы Президентының рәсми сайтының тиешле бүлекчәсенә керү гамәлгә ашырыла.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупция күренешләре турында хәбәр итү өчен «Ышаныч телефоннары» бүлекчәсе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларына коррупция фактлары турында мөрәҗәгатьләренең (хәбәрләренең) тоткарлыксыз юнәлтү турында гражданнар һәм оешмалар өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә ала (ришвәт кысу очракларында, дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләүнең хокуксыз таләпләрендә һ.б.).

Әлеге бүлекчәдә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган телефон номеры, вазыйфаи затларның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, шулай ук «ышаныч телефоны»на кергән хәбәрләрне карау нәтиҗәләре (кварталга кимендә бер тапкыр) күрсәтелә.

1.3. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы программасы» бүлегендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы муниципаль программасы тексты булырга тиеш, әлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган текст аның реквизитларын күрсәтеп, ә аңа үзгәрешләр кертелгән очракта - күрсәтелгән программага үзгәрешләр кертү турында хокукый актлар текстлары.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы программасы әлеге бүлекчәдә актуаль (гамәлдәге) редакциядә урнаштырыла.

Әлеге бүлекчәдә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы программасының үтәлеше турында хисап мәгълүматы алу өчен гиперссылка буенча күчү тәэмин ителергә тиеш.

1.4. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» гиперссылкасы буенча күчкәндә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган, күрсәтелгән мәгълүматлар булган бүлекчәгә керү гамәлгә ашырылырга тиеш (алга таба – муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр). Күрсәтелгән мәгълүматлар, шул исәптән алдагы елларда да, өченче зат тарафыннан аларга керү мөмкинлеген чикләмичә, шулай ук аларны урнаштыру вакытын чикләмичә урнаштырылырга тиеш.

Муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәткәрләрне хисап чорында биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар, законнарда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, бастырып чыгарыла.

1.5. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупцион хәвеф-хәтәрләргә бәйле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге» бүлегендә күрсәтелгән вазыйфалар исемлеге, шулай ук аларга тиешле үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат (хокукый актлар) булырга тиеш.

1.6. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе» бүлекчәсендә күрсәтелгән комиссия турында нигезләмә, комиссиянең бер елга эш планы, комиссиянең уздырылган утырышлары турында һәм комиссия кабул иткән карарлар турында мәгълүмат, аның актуаль составы урнаштырылырга тиеш.

1.7. «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» бүлекчәсендә күрсәтелгән комиссия турында нигезләмә, комиссиянең бер елга эш планы, комиссиянең уздырылган утырышлары турында һәм комиссия кабул иткән карарлар турында мәгълүмат, аның актуаль составы урнаштырыла.

Күрсәтелгән комиссия карарларының шәхси мәгълүматлар булырга мөмкин булуын исәпкә алып, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән карарларны бастырып чыгару мондый мәгълүматларның начарлануы белән гамәлгә ашырыла.

1.8. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затлар» гиперсылтама буенча күчкәндә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында җаваплы затларны билгеләү турындагы актларга, шулай ук күрсәтелгән затларның вазыйфаи инструкцияләренә керү тәэмин ителергә тиеш.

Әлеге бүлекчәдә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затларның контакт мәгълүматлары (хезмәт телефоны номеры, факс һәм электрон почта адресы) күрсәтелергә тиеш.

1.9. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру чаралары турында хисаплар» бүлекчәсендә Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына тапшырылган коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында хисаплар урнаштырыла.

1.10. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары уздырган муниципаль норматив хокукый актларның һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы нәтиҗәләре» бүлекчәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актларга һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы үткәрелгән экспертиза турында факттагы мәгълүматлар булырга тиеш, шул исәптән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре турында да, сайтта урнаштырылган муниципаль норматив хокукый актлар проектларына карата уздырылган (мәгълүмат текст һәм график төрләрендә урнаштырылырга мөмкин).

1.11. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсенең органнары һәм вазыйфаи затлары эшләгән муниципаль норматив хокукый актларга һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза» гиперсылтама буенча (бүлекчәсенә) күчкәндә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына бәйсез экспертлардан бәяләмәләрне,

шулай ук мондый бәяләмәләрне кабул итү өчен җаваплы затларның контакт мәгълүматларын кабул итә башлау һәм төгәлләү даталарын күрсәтеп, керү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш. (Ф.И.О.и., хезмәт телефоны номеры һәм электрон почта адресы).

1.12. «Җәмәгатьчелек фикерен сораштыру, анкеталаштыру» бүлекчәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы органнарында һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларында коррупциянең торышы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары функцияләрен башкарганда йә физик (юридик) затларга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә административ киртәләр булу һәм башка материаллар турында аларның фикерен өйрәнү максатларында гражданнар өчен анкеталар яисә сораштыру кәгазьләре урнаштырыла.

1.13. «Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең коррупциягә каршы тору турындагы карарлары» гиперсылтамасы буенча күчкәндә федераль законнарга гиперсылтамаларның тулы актуаль исемлеге булган бүлекчәгә керү, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең коррупциягә каршы тору өлкәсендәге карарлары кертелергә тиеш.

Мәгълүмат күрсәтелгән документлар текстын эзләү һәм күчермәләү мөмкинлеген тәэмин итүче форматта урнаштырыла.

Коррупциягә каршы тору өлкәсендә норматив хокукый актлар шулай ук өстәмә рәвештә аларның оригиналларының график образлары рәвешендәге сайтта урнаштырылырга мөмкин.

1.14. “Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының коррупциягә каршы тору турындагы карарлары” бүлекчәсен тулыландыру әлеге таләпләрнең 1.13 пунктында каралган кагыйдәләр нигезендә башкарыла.

1.15. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы тору турындагы муниципаль норматив хокукый актлары” бүлекчәсен тулыландыру әлеге таләпләрнең 1.13 пунктында каралган кагыйдәләр нигезендә башкарыла.

1.16. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы " бүлекчәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе Кодекслары урнаштырыла, алар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы һәм Башкарма комитеты карарлары белән расланган, аларда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тору стандартын аерып күрсәтеп.

1.17. «Методик материаллар, докладлар, хисаплар, күзәтүләр, статистик һәм коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка мәгълүмат» гиперсылтамасы буенча күчкәндә тиешле материалларга керү гамәлгә ашырыла (гамәлдәге законнар таләпләрен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне үз эченә алган ведомствоара киңәшмәләр беркетмәләреннән өземтәләргә, методик тәкъдимнәргә,

законнарны аңлаткан хатларга, өземтәләргә).

Докладлар, хисаплар, статистик мәгълүмат, формалар, бланклар һәм башка документлар файллар рәвешендә кулланучыларның техник чараларында аларны саклап калу мөмкинлеген тәэмин итә торган форматта урнаштырыла.

## III. «Коррупциягә каршы тору» бүлеген актуальләштерү

Мәгълүмат урнаштыру һәм аны “Коррупциягә каршы тору” бүлегендә актуальләштерү әлеге таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.